# КАРАР

**Татарстан Республикасы Биектау муниципаль районы Алан-Бәксәр авыл җирлегенә кергән Алат спиртзаводы авылы торак пунктында гражданнар җыены нәтиҗәләре турында**

2025 ел, 13 ноябрь № 3

«Гавами хакимиятнең бердәм системасында җирле үзидарәне оештыруның гомуми принциплары турында» 2025 елның 20 мартындагы 33-ФЗ номерлы Федераль законның 45, 69 маддәләре, «Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында» 2004 елның 28 июлендәге 45-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законының 35 статьясы, “Татарстан Республикасы Биектау муниципаль районы Алан-Бәксәр авыл җирлеге” муниципаль берәмлеге Уставының 24 статьясы, Татарстан Республикасы Биектау муниципаль районы Алан-Бәксәр авыл җирлеге Советының «Татарстан Республикасы Биектау муниципаль районы Алан-Бәксәр авыл җирлеге составына керүче торак пунктларда гражданнар җыенын әзерләү һәм үткәрү тәртибе турында Нигезләмәне раслау хакында» 2019 елның 22 октябрендәге 188 номерлы (Советның 19.05.2020 ел. №219, 13.10.2020 ел №11 карарлары редакциясендә) карарына нигезләнеп, "Татарстан Республикасы Биектау муниципаль районы Алан-Бәксәр авыл җирлегенә кергән Алат спиртзаводы авылы территориясендә яшәү урыны буенча теркәлгән һәм даими яшәүче балигъ булган һәр кешедән 2026 елда 800 сум күләмендә үзара салым кертүгә һәм җыелган акчаларны түбәндәге эшләрне:

- урамнарны тышкы яктырту челтәрләрен, трансформатор һәм башка подстанцияләрне һәм алар астындагы мәйданчыкларны, бүлү пунктларын һәм электр элемтәләрен тәэмин итү һәм электр энергиясен тапшыруны гамәлгә ашыру өчен билгеләнгән башка җиһазларны ремонтлау;
- урамнарны яктырту җайланмаларын төзекләндереп тору;
- янгын куркынычсызлыгының беренчел чараларын тәэмин итү;
- янгын резервуарларын (янгын сусаклагычларын) урнаштыру, янгын пирслары төзү, ремонтлау;
- торак пункт чикләрендә гомуми файдаланудагы җирле әһәмиятле автомобиль юлларын төзү, ремонтлау, карап тоту;
- каты коммуналь калдыкларны туплау мәйданчыклары төзү, каты коммуналь калдыкларны җыю өчен контейнерлар сатып алу, рөхсәтсез чүплекләрне бетерү;
- торак пунктның башка территорияләрен төзекләндерүне башкару буенча җирле әһәмияттәге мәсьәләләрне хәл итүгә юнәлдерүгә Сез ризамы?”

«ӘЙЕ» «КАРШЫ».

соравы буенча 2025 елның 13 ноябрендә уздырылган гражданнар җыены нәтиҗәләре буенча беркетмә төзелде.

Гражданнар җыены нәтиҗәләре турында беркетмә нигезендә:

җыенда катнашучылар исемлегенә сайлау хокукына ия булган 74 (Җитмеш дүрт) граждан кертелгән, тавыш бирүдә катнашкан гражданнар саны - 40 кеше, бу 54,05 % тәшкил итә;

тавыш бирү нәтиҗәләре буенча, җыенда катнашучыларның тавышлары түбәндәгечә бүленде:

«ӘЙЕ» позициясе өчен гражданнар җыенында катнашучы 40 (Кырык) кеше тавыш бирде; «КАРШЫ» позициясе өчен җыенның 0 (ноль) катнашучысы тавыш бирде.

Бәян ителгәннәр нигезендә, халык җыены карар итте:

1. Татарстан Республикасы Биектау муниципаль районы Алан-Бәксәр авыл җирлегенә кергән Алат спиртзаводы авылы торак пунктында гражданнар җыенын узган, гражданнар җыенының нәтиҗәләрен дөрес дип танырга.
2. 2026 елда Татарстан Республикасы Биектау муниципаль районы Алан-Бәксәр авыл җирлеге Алат спиртзаводы авылы территориясендә яшәү урыны буенча теркәлгән һәм даими яшәүче һәр балигъ кешедән 800 сум күләмендә үзарасалым кертергә.
3. Җыелган акчаларны җирле әһәмияттәге түбәндәге эшләрне башкаруга юнәлдерергә:

- урамнарны тышкы яктырту челтәрләрен, трансформатор һәм башка подстанцияләрне һәм алар астындагы мәйданчыкларны, бүлү пунктларын һәм электр элемтәләрен тәэмин итү һәм электр энергиясен тапшыруны гамәлгә ашыру өчен билгеләнгән башка җиһазларны ремонтлау;

- урамнарны яктырту җайланмаларын төзекләндереп тору;

- янгын куркынычсызлыгының беренчел чараларын тәэмин итү;

- янгын резервуарларын (янгын сусаклагычларын) урнаштыру, янгын пирслары төзү, ремонтлау;

- торак пункт чикләрендә гомуми файдаланудагы җирле әһәмиятле автомобиль юлларын төзү, ремонтлау, карап тоту;

- каты коммуналь калдыкларны туплау мәйданчыклары төзү, каты коммуналь калдыкларны җыю өчен контейнерлар сатып алу, рөхсәтсез чүплекләрне бетерү;

- Алат спиртзаводы авылы торак пунктның башка территорияләрен төзекләндерүне башкару.

4. Әлеге карарны мәгълүмат стендларында, Татарстан Республикасы Биектау муниципаль районының мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендәге рәсми сайтында: http://vysokaya-gora.tatarstan.ru веб-адрес буенча «авыл җирлекләре» бүлегендә һәм Интернет мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендәге «Татарстан

Республикасы хокукый мәгълүмат рәсми порталында»: http://pravo.tatarstan.ru веб-адрес буенча урнаштырып халыкка җиткерергә.

5. Әлеге карарны Татарстан Республикасы муниципаль норматив хокукый актлары Регистрына кертү өчен җибәрергә.

Гражданнар җыенында рәислек итүче,
Алан-Бәксәр авыл җирлеге башлыгы: З.Р.Гарифуллина